**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НАРМОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422630 с. Нармонка,
ул. Молодежная , д.12 а
тел: 4-62-24

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НАРМОНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422630 Нармонка авылы,
Яшьләр урамы, 12 а нчы йорт,
тел: 4-62-24

**2024 елның «23» гыйнвары** **1 номер**

# КАРАР

## «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү ү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон (үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алып), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә карар бирәм**:**

1. 2024 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен, 1, 2 кушымталар нигезендә, 8370,20 сум күләмендә дип билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. 2024 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге Башкарма комитетының «2024 елга җирләү буенча гарантияле хезмәтләр күрсәтү исемлегенә тарифларны раслау турында» 2023 елның 24 гыйнварындагы 2 номерлы карары үз көчен югалтуын танырга.
3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **И.Ф.Мөбәракшин**

Татарстан Республикасы Нармонка авыл
җирлеге Башкарма комитетының
2024 елның 23 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
1 кушымта

**2024 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр күрсәтү исемлеге бәяләре.**

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләр бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табутны һәм күмү өчен кирәк булган башка әйберләрне бирү һәм җиткерү | 4929,94 |
| 3. Зиратка мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) илтү | 1324,48 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү)ү) | 2115,78 |
| БАРЛЫГЫ | **8370,20** |

Татарстан Республикасы
Нармонка авыл җирлеге Башкарма комитетының
2024 елның 23 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
2 кушымта

**2024 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр күрсәтү исемлеге бәяләре**

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләр бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне төрү | 708,31 |
| 3. Табутны һәм күмү өчен кирәк булган башка әйберләрне бирү һәм җиткерү | 4221,63 |
| 4. Зиратка мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) илтү | 1324,48 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2115,78 |
| БАРЛЫГЫ | **8370,20** |